СОВЕТ
БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2025 елның 17 декабре Олы Ачасыр авылы № 17

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2020 елның 30 сентябрендәге 8 номерлы «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәт хакы күләмен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 сентябрендәге 99 номерлы, 2024 елның 3 июнендәге 185 номерлы, 2024 елның 27 ноябрендәге 203 номерлы, 2025 елның 287 апрелендәге 222 номерлы карарлары белән кертелгән үзрәрешләр белән)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 ноябрендәге 994 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының хезмәтенә түләү күләмнәрен, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын билгеләү турында» 2024 елның 3 июнендәге 8 номерлы (Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2022 елның 26 сентябрендәге 99 номерлы, 2024 елның 3 июнендәге 185 номерлы, 2024 елның 27 ноябрендәге 203 номерлы, 2025 елның 287 апрелендәге 222 номерлы) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1). 1 пунктта:

1.1) беренче абзацта «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1.2) икенче абзацта «21 091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә һәм 27 208 (егерме җиде мең ике йөз сигез) сум күләмендә айлык акчалата бүләкләү» сүзләрен «23 201 (егерме өч мең ике йөз бер) сум күләмендә һәм 29 930 (егерме тугыз мең тугыз йөз утыз) сумм күләмендә айлык акчалата бүләкләү» сүзләренә алмаштырырга;

2). 2 пунктта:

2.1) беренче абзацта «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

2.2) икенче абзацта «21 091 (егерме бер мең туксан бер) сум күләмендә» сүзләрен «23 201 (егерме өч мең ике йөз бер) сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга»;

3) 3 пунктта «2025 елның 1 маеннан» сүзләрен «2026 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга;

4) «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2025 елның 17 декабрендәге 17 номерлы карарына кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНДӘ МУНИЦИПАЛЬ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРНЕҢ ВАЗЫЙФАИ ХЕЗМӘТ ХАКЫ КҮЛӘМЕ

| **Муниципаль хезмәт вазыйфаларының атамалары** | **Вазыйфаи хезмәт хакының айлык күләме, сум** |
|---|---|
| Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре) | 22515 |
| Әйдәп баручы белгеч | 18791 |

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл жирлеге<br>башлыгы, Совет рәисе И.М. Саттаров